ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫЃ ДЂЊЛЂТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 145

П Р И К А З    Б О Е Р Ы К

«22» май 2017 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең "Күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрелүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциячел булмаган оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшырылу тәртибен раслау турында" 2013 елның 15 ноябрендәге 151 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" һәм "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында" Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү турында" 2016 елның 28 декабрендәге 498-ФЗ Федераль законны һәм "Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрелүне оештыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 27 апрелендәге 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең "Күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрелүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциячел булмаган оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшырылу тәртибен раслау турында" 2013 елның 15 ноябрендәге 151 номерлы боерыгына (28.01.2014 № 15, 05.03.2014 № 35, 28.09.2015 № 469 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Дәүләт капиталь ремонт программасын формалаштыруның һәм үтәүнең һәм торак фонды объектларының торышын мониторинглауның мәгълүмати-аналитик системасын – дәүләт капиталь ремонт программасын формалаштыруның һәм мониторинглауның һәм торак фонды объектларының торышын мониторинглауның дәүләт мәгълүмат системасы итеп билгеләргә".

2. Тәртипкә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.2 пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ТКХ ДМС" – торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – система) – торак фонды, күпфатирлы йортларда гомуми милек белән идарә итү буенча хезмәтләрнең, күпфатирлы йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләрнең бәясе һәм исемлеге, коммуналь хезмәтләрне күрсәтү һәм коммуналь хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган ресурларны җиткерү, торак бина һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү зурлыгы, күрсәтелгән түләү буенча бурыч турында, коммуналь һәм инженерия инфраструктурасы объектлары турында мәгълүматларны, шулай ук торак-коммуналь хуҗалыгы белән бәйле булган бүтән мәгълүматларны җыюны, эшкәртүне, саклауны, бирүне, урнаштыруны һәм алардан файдалануны тәэмин итә торган программалы, техник чаралар һәм мәгълүмат технологияләре нигезендә вазыйфалый торган бердәй федераль үзәкләштерелгән мәгълүмат системасы";

1 бүлекнең 1.2 пунктындагы уникенче абзацта "ТФМ МАС" сүзләрен "ТКХ ДМС" сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекнең аталышындагы "ТФМ МАС" сүзләрен "ТКХ ДМС" сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.1 пунктындагы "ТФМ МАС" сүзләрен "ТКХ ДМС" сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.3 пунктындагы "ТФМ МАС" сүзләрен "ТКХ ДМС" сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.4 пунктындагы "ТФМ МАС" сүзләрен "ТКХ ДМС" сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.5 пунктындагы "ТФМ МАС" сүзләрен "ТКХ ДМС" сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.2 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2. Махсус счет хуҗасы кушымта булып килүче формалар (1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче кушымталар) нигезендә махсус счетта капиталь ремонт фондын сайлау турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә тиешле күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турындагы хәбәрләмәне; биналарның милекчеләренең фонд формалаштыру ысулын сайлау турындагы гомуми җыелышларының беркетмәләре күчермәләрен; махсус счет ачылу турында банк белешмәсен; биналарның милекчеләренең күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлавы турында гомуми җыелыш беркетмәсенең күчермәсен; күпфатирлы йорт турындагы белешмәләрне (күпфатирлы йортның катлары, гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак

биналарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнарның саны, эксплуатациягә кертелгән елы, соңгы мәртәбә капиталь ремонт үткәрелгән елы һ.б.); капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә исәпләнгән акчаларның күләме турындагы мәгълүматны; капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә килгән акчаларның күләме турындагы мәгълүматны; махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акчаларның күләме турындагы мәгълүматны; биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр килү һәм махсус счеттагы акчаларның калдык өлеше турындагы белешмәләрне; капиталь ремонт үткәрелүгә займ шартнамәсен һәм (яисә) кредит шартнамәсен төзү турындагы мәгълүматларны, мондый шартнамәләрнең таныкланган күчермәләрен теркәп, ТКХ ДМС системасында урнаштыра";

3 бүлекнең 3.2 пунктында түбәндәге эчтәлекле 3.2.1, 3.2.2 һәм 3.2.3 пунктчаларын өстәргә:

"3.2.1. Капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә исәпләнгән акчаларның күләме турындагы белешмәләр Россия Федерациясе Торак кодексының 175 статьясының 3.1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан махсус счет хуҗасына ай саен, хисап тапшырыла торган айдан соң килә торган айның бишенче көненә кадәр, шул исәптән электрон рәвештә, 9 нчы кушымтага туры китерелгән рәвештә тапшырыла.";

"3.2.2. Төбәк операторы биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондларын счетта, төбәк операторы счетында формалаштыручы күпфатирлы йортлар турындагы, шулай ук мондый күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр килүе турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына ай саен, хисап тапшырылучы айдан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр, шул исәптән электрон рәвештә, Татарстан Республикасының дәүләт торган күзәтчелеге органы билгеләгән тәртиптә тапшырырга тиеш.";

"3.2.3. Махсус счет хуҗасы капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә исәпләнгән акчаларның күләме турындагы белешмәләрне, капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә килгән акчаларның күләме турындагы белешмәләрне, махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акчаларның күләме турындагы белешмәләрне, махсус счетта акчаларның калдык өлеше турындагы белешмәләрне, капиталь ремонт үткәрелүгә займ шартнамәсе һәм (яки) кредит шартнамәсе төзелү турындагы белешмәләрне, мондый шартнамәләрнең таныкланган күчермәләрен теркәп, Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына ай саен, хисап тапшырылучы айдан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр, шул исәптән электрон рәвештә, Татарстан Республикасының дәүләт торган күзәтчелеге органы билгеләгән тәртиптә тапшырырга тиеш.";

Тәртипкә 9 нчы кушымта (теркәлә) өстәргә.

3. Юридик бүлек башлыгына (О.В. Сидоров) дәүләт теркәвенә алу өчен бу Боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлеге башлыгына (И.С. Начвин) бу Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң ун эш көне эчендә аны "Интернет" мәгълүмати-коммуникацияләр

челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең
15.11.2013 № 151 боерыгына
9 нчы кушымта

Милекчеләре капиталь ремонт фондын махсус счетта формалаштыру турында карар кабул иткән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауга кертемнәр рәвешендә исәпләнгән акчаларның күләме турында
БЕЛЕШМӘЛӘР

| № п/п | Йортның адресы | Биналарның мәйданнары (кв.м.) | | | Исәпләнде (сум) | | | Түләнде (сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | шул исәптән: | | Барлыгы | шул исәптән: | | Барлыгы | шул исәптән: | |
| | | | торак биналар | торак булмаган биналар | | торак биналарның милекчеләренә | торак булмаган биналарның милекчеләренә | | торак биналарның милекчеләре тарафыннан | торак булмаган биналарның милекчеләре тарафыннан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| | | | | | | | | | | |